ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
МАРИ ТӘКӘШЕ АВЫЛЫНДА ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 30 ноябреннән № 24

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, 1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен бер тапкыр түләүдән тыш, аны 150 сум итеп билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Мари Тәкәше авылында юлларны кыш көне кардан чистарту.

Мари Тәкәше авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлау һәм койма белән әйләндереп алу.

3. Мари Тәкәше авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru«Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы Кәшәфетдинов И.И.